ГЛАВА ЛЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел 9 нчы август № 3

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» 2003 елның 10 гыйнварындагы 17-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Ләке авыл җирлегенең 2021 елның 28 декабрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар чыгарды:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» проектын әзерләү комиссиясе - үткәрү датасы һәм вакыты - 2023 елның 24 августы 14.00 сәгатьтә;

- үткәрелү урыны - Ләке авылы, Мәктәп урамы, 1, авыл җирлеге бинасы утырышлар залында;

- язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Татарстан Республикасы Сарман районы, Ләке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт адресы буенча Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитетына кертелергә мөмкин,(эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 11.30 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын әзерләү комиссиясе:

- гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 нояббрендәге 23 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Ләке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

4. Башлыкның әлеге карарын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында http/ sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

«Ләке авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы урынбасары В.Н.Сапожников

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгының карарына кушымта 2023 елның 9 нчы августы № 3

**Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә кертү турында**

1. 2 бүлекнең 4.1 пунктын төшереп калдырырга;
2. 3.6.1 пунктының «й» пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;
3. 3.7.2 пунктындагы «д» пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;
4. 3 бүлекнең 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында «(тимер юл)» сүзләрен төшереп калдырырга;
5. 4 бүлекнең 4.2.7 пунктын төшереп калдырырга.